ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРУ, ӘЙЛӘНЕШЕ
һӘМ СЫЙФАТЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН
ТӘЭМИН ИТҮ һӘМ КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫҢ
ХОКУКЛАРЫН
ЯКЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь
инспекциясе)

# БОЕРЫК

_07.11.2017_ № _12-07/195_

Казан ш.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь
инспекциясендә Татарстан Республикасы
дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы
вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү)
конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында

“Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль закон, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 1 февраль, 2005 ел, № 112 Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында нигезләмәне (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. “Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында” 27.01.2017 ел, №12-07/4 Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең административ һәм суд практикасы бүлегенә (Эйдинов Б.Г.) бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Җ.Й. Әхмәтханов

Татарстан Республикасы Дәүләт
алкоголь инспекциясенең 07.11.2017
№ 12-07/195 боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмәдә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү буенча Конкурс комиссиясенең (алга таба – конкурс комиссиясе) составы, эш сроклары һәм тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү методикасы билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс (алга таба – конкурс) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә керүенә бертигез хокукын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукын тәэмин итә.

1.2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә конкурс “Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 22 статьясы, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 1 февраль, 2005 ел, № 112 Россия Федерациясе Президенты Указы, “Татарстан Республикасының дәүләти гражданлык хезмәте турында” 16 гыйнвар, 2003 ел, № 3-ТРЗ, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау хакында” 14 март, 2011 ел, № УП-127 Татарстан Республикасы Президенты Указы, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест оештыру мәсьәләләре” 11 декабрь, 2015 ел, № УП-1192 Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә үткәрелә.

Конкурс дәүләти гражданлык хезмәте (алга таба – гражданлык хезмәте) вазыйфасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә вакантлы вазыйфа биләүгә конкурс, Федераль закон буенча конкурс үткәрелергә тиешле вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасы булганда, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба –

җитәкче) карары буенча игълан ителә.

1.4. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар резервына кертүгә конкурс, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен белгечләргә ихтимал ихтыяҗын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар резервын еллык бәяләү нәтиҗәләре буенча, кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлеге тарафыннан оештырыла.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар резервына кертүгә конкурс Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең конкурс комиссиясе тарафыннан бу Нигезләмәдә күздә тотылган тәртиптә үткәрелә.

1.5. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә түбәндәге очракларда вакантлы вазыйфа биләүгә конкурс үткәрелми:

- “җитәкчеләр” һәм “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категорияләрендә дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары вәкаләтләренә билгеле бер срокка билгеләнгәндә;

- вакытлы хезмәт контракты төзегәндә;

- Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә күздә тотылган очракларда, гражданлык хезмәткәрен башка гражданлык хезмәтенә билгеләгәндә;

- гражданлык хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән гражданлык хезмәткәрен (гражданин) гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

1.6. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә вакантлы вазыйфа биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

- вазыйфаи бурычлар Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы белән расланылган вазыйфалар исемлеге буенча дәүләт сере булып торган мәгълүматлардан файдалануга бәйле вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле дәүләт хезмәтенең аерым вазыйфаларына билгеләгәндә;

- гражданлык хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә керүче гражданлык хезмәте вазыйфасына җитәкче карары буенча билгеләгәндә.

1.7. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

- Россия Федерациясе гражданнарының үзләренең сәләте һәм һөнәри әзерлеге нигезендә дәүләт хезмәтенә керүенә бертигез хокукын, шулай ук дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукын тәэмин итү;

- Федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актлары нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килеп, конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми саныннан гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен иң кулай кандидатларны сайлап алу;

- гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар резервын булдыру.

1.8. Конкурслар үткәргәндә хәл ителә торган бурычлар:

- конкурс биремнәрен һәм процедураларын үтәгәндә барлык кандидатлар өче бертигез шартлар тәэмин итү;

- кандидатларны һөнәри яктан әһәмиятле объектив критерийлар нигезендә бәяләү;

- конкурста катнашучы затлар арасыннан, конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән, гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфаларының (кадрлар резервына кертү) тиешле таләпләренә туры килердәй затларны билгеләү.

II. Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм аның эше тәртибе

2.1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә конкурс үткәрү өчен җитәкче боерыгы белән даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе булдырыла. Комиссия составына кертелгән вазыйфаи затларның персональ составы үзгәртелгәндә, җитәкче боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

2.2. Конкурс комиссиясе рәисеннән, рәисе урынбасары, секретаре һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, аның хокуклары һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе секретаре комиссия эшен тәэмин итә (гаризалар кабул итә, делолар булдыра, конкурс комиссияләрен, карарларын рәсмиләштерә һ.б.).

2.4. Конкурс комиссиясе составына җитәкче һәм (яки) вәкаләтле гражданлык хезмәткәрләре (шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар мәсьәләсе һәм коорупциягә каршы көрәш бүлегеннән, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең административ һәм суд практикасы бүлегеннән) һәм гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрелә торган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең структур подразделениесеннән вәкаләтле гражданлык хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук гражданлык хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча бәйсез эксперт-белгечләр сыйфатында җитәкче запросы буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакырыла торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар вәкилләре, экспертларның персональ мәгълүматлары күрсәтелмичә генә, керә.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.5. Вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт сере булып торчы мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе законы нигезләмәләреннән чыгып булдырыла.

2.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясардай мәнфәгатьләр бәрелеше килеп чыгу ихтималын юкка чыгарырдай итеп булдырыла.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы гражданлык хезмәтенең вакантлы

вазыйфасына (кадрлар резервына кертү өчен) кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән ике өлеше катнашканда – узды, дип санала. Фәкать гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары катнашында гына конкурс комиссиясе утырышын үткәрү рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе карары кандидат югында кабул ителә.

2.9. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары утырышта катнашкан әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү нигезендә кабул ителә. Тавышлар бертигез булганда, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәл иткеч була.

2.10. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кабул ителә торган карарлар (комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре) конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, аңа утырышта катнашкан комиссия рәисе, рәисе урынбасары, секретаре һәм комиссия әгъзалары кул куя.

2.11. Конкурсны турыдан-туры оештыру һәм аны үткәрүне, конкурс комиссиясе эшен тәэмин итүне Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлеге хәл итә.

## III. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурска Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) дәгъва кылучы кандидатларга карата таләпләргә туры килеп, бу Нигезләмәнең 3.4. пунктында күрсәтелгән документларны бу Нигезләмәнең 3.7. пунктында күздә тотылган срокта тапшырган гражданнар кертелә.

3.2. Гражданин (гражданлык хезмәткәре) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасын) биләү өчен квалификация таләпләренә туры килмәвенә, шулай ук Федераль законда билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә конкурска кертелми.

3.3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар резервына Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 2 яки 3 пунктында яисә 59.1 статьясының 2 яки 3 пунктында күздә тотылган дисциплинар шелтә алган дәүләт хезмәткәре кертелә алмый.

3.4. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) дәгъва кылучы кандидатларга карата таләпләр дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән.

3.5. Конкурста катнашуга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданины Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә тапшыра:

- шәхсән гариза (бу Нигезләмәгә №1 кушымта);

- Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган формада тутырылган һәм имзаланган анкета, фотосурәт белән;

- паспорт яки аны алыштыручы документ күчермәсен (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

- кирәкле һөнәри белемне, квалификация һәм эш стажын раслаучы документлар:

-хезмәт кенәгәсе күчермәсен (хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлегенә тәүге тапкыр керешү очракларыннан тыш), нотариуста яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган, яки гражданинның хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлеген раслаучы башка документлар;

- белеме һәм квалификациясе турында документлар күчермәләре, шулай ук гражданинның теләгенә карап – өстәмә һөнәри белем бирү нәтиҗәләре буенча квалификациясен күтәрү яки квалификация үзләштерүне раслаган документлар, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турында документлар, нотариуста яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган;

- Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 14 декабрь, 2009 ел, №984н боерыгы белән расланган гражданинның гражданлык хезмәтенә керүенә яки аны башкаруына комачаулардай авырулардан интекмәве турында документ (001-ГС/у учет формасы);

- Федераль законда, башка Федераль законнарда Россия Федерациясе Президенты Указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында күздә тотылган башка документлар.

3.6. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә гражданлык хезмәте вазыйфасын биләп, конкурста катнашуга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре җитәкчер исеменә гариза тапшыра.

Башка дәүләт органында вазыйфа биләп, конкурска катнашуга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе исеменә гариза һәм фотосурәте белән, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган формада үзе тутырып имзалаган һәм үзе гражданлык хезмәте вазыйфасын били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте раслаган анкета тапшыра.

3.7. Гражданин (гражданлык хезмәте) ризалыгы белән дәүләт сере һәм закон нигезендә сакланыла торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматлар белән эшләүгә рөхсәтне рәсмиләштерү процедурасы үткәрелә, гражданин (гражданлык хезмәткәре) мондый мәгълүматлардан файдалануга бәйле гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва кылганда.

Гражданинның җитәкче исеменә тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган мәгълүматлар Россия Федерациясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә автомат рәвештә тикшерелә.

3.8. Бу Нигезләмәнең 3.4 һәм 3.5 пунктларында күрсәтелгән документлар аларны кабул итү турында интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы рәсми сайтына урнаштырылганнан соң 21 календарь көне эчендә гражданин (гражданлык хезмәткәре) тарафыннан шәхсән, почта аша яки, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, әлеге мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә, дәүләт органына тапшырыла.

Документларны нигезле сәбәпсез вакытында тапшырмау, тулы күләмендә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан (гражданлык хезмәткәре) аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Документлар нигезле сәбәпсез вакытында тапшырылмаганда, тулы күләмендә тапшырылмаганда яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырылганда, җитәкче

аларны кабул итү срокларын күчерүгә хокуклы.

## IV. Конкурс үткәрү методикасы

4.1. Конкурс үткәргәндә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәгән кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү ысулларына нигезләнгән конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү критерийләре Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең гражданлык хезмәте вазыйфаларына карата куела торган квалификация таләпләре нигезендә эшләнгән.

Конкурста катнашучыларны бәяләү критерийләре һәм сайлап алынган ысуллар конкурс үткәрелә торган вазыйфалар төркеменә һәм категориясенә бәйле рәвештә үзгәртелергә мөмкин.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын узу нәтиҗәләре нигезендә хәл ителә.

4.4. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.4.1. Беренче этапта Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлеге оештыра:

- Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтларына конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында белдерү, шулай ук конкурс турында түбәндәге мәгълүматларны: гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы атамасын, әлеге вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләрен, гражданлык хезмәтен үтү шартларын, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) дәгъва кылучы кандидатлар тапшыра торган документлар һәм материаллар нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакытын, әлеге документларны кабул итүне тәгәлләү срогын, конкурсны үткәрүнең күздә тотылган датасын, аны үткәрү урыны һәм тәртибен, башка мәгълүмати материалларны әзерләү һәм урнаштыруны;

кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшерүне;

гражданинның (гражданлык хезмәткәре) квалификация таләпләренә (һөнәри белем бирү дәрәҗәсе, гражданлык хезмәте (гражданлык хезмәтенең башка төрләре) стажы яки белгечлек буенча эш стажы (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле һөнәри белемнәре һәм күнекмәләре) туры килүен тикшерүне..

4.4.2. Тикшерү барышында федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары нигезендә гражданинның гражданлык хезмәтенә керүенә комачаулардай хәлләр ачыкланганда, гражданинга җитәкче тарафыннан, язмача рәвештә, конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турында хәбәр ителә. Гражданин конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвештә тапшырган очракта конкурста катнаштырудан баш тарту нигезләре турында белдерү кәгазе аңа, дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә

–

җибәрелә.

4.4.3. Конкурста катнашуга кертелмәгән вакантлы вазыйфа биләүгә (кадрлар резервына кертү) дәгъва кылучы бу механизмга Россия Федерациясе законы нигезендә шикаять белдерүгә хокуклы.

4.4.4. Конкурсның беренче этабын төгәлләү шарты булып Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе гражданлык хезмәтенең бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасы) билгеләнгән тиешле квалификация таләпләренә туры килердәй кимендә ике кандидатның булуы тора, бу кандидатларны алга таба сайлап алу мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаган очракта яки вазыйфага карата квалификация таләпләренә туры килердәй бер генә кандидат булганда, конкурс, узмады, дип танала. Бу очракта бердәнбер кандидатка, кандидатларның тиешле санда булмавы сәбәпле, конкурсны, узмады, дип тану турында язмача хәбәр җибәрелә.

4.4.5. Конкурсның беренче этабы тәмамланганнан соң җитәкче конкурсның икенче этабын үткәрү датасы (конкурста катнашу өчен документларны кабул итү төгәлләнгәннән соң 30 календарь көненнән дә соңга калмыйча), вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Дәүләт сере яки закон нигезендә саклана торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматлар белән эшләүгә рөхсәт рәсмиләштерү очрагында җитәкче конкурсның икенче этабын үткәрү срогын билгели.

Дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре секторы конкурсның икенче этабы башланырга кимендә 15 календарь көне кала Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтына һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтына конкурс үткәрү датасы, урыны һәм вакыты, конкурста катнашуга рөхсәт ителгән кандидатлар исемлеге урнаштыра һәм кандидатларга язмача рәвештә тиешле хәбәрләр җибәрә, шул ук вакытта конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвештә җибәргән кандидатларга – әлеге мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.

4.4.6. Конкурсның икенче этабында түбәндәгеләр хәл ителә:

- конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү;

- Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертү) җиңүчене билгеләү турында карар кабул итү.

4.4.7. Конкурс үткәргәндә, конкурс комиссиясе кандидатларны белеме, гражданлык хезмәте яки башка дәүләт хезмәте үтү, башка хезмәт эшчәнлеген алып бару турында тапшырылган документлары, шулай ук тест үткәрү һәм кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләүнең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәүче ысулларыннан файдаланып, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә кандидатлар дәгъва кыла торган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасы) буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча тест һәм индивидуаль әңгәмәдән файдаланып, кандидатларны бәяли.

4.4.8. Кандидатлар өчен тест сынаулары электрон рәвештә үткәрелә. Конкурс комиссиясе кандидатларга тест сынаулары өчен сораулар исемлеген әзерли. Дөрес булмаган җавапларның рөхсәт ителгән саны 25 проценттан артып китмәскә тиеш.

Сораулар исемлеге белән барлык кандидатларга танышу мөмкинлеге тудырылырга тиеш. Тест сораулар исемлеге нигезендә төзелә, һәм ул конкурста катнашучыларның түбәндәге законнар һәм норматив-хокукый актларны ни дәрәҗәдә белүләрен тикшерүне тәэмин итәргә тиеш:

-Россия Федерациясе Конституциясен һәм Татарстан Республикасы Конституциясен;

- дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын;

- Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе турында нигезләмәне;

- гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасының вазыйфаи регламентын;

- структур подразделение эшчәнлеге юнәлеше буенча норматив-хокукый актларны.

Кандидатларга тест биремнәренә җаваплар әзерләү өчен бер үк төрле вакыт бирелә.

4.4.9. Реферат язу өчен Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә кандидатлар дәгъва кыла торган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфалары) буенча вазыйфаи бурычларны һәм вәкаләтләрне үтәүгә бәйле сораулардан файдалану тәкъдим ителә. Рефератлар темаларын конкурс комиссиясе билгели.

Кандидатлар бер үк темага реферат яза һәм аларга аны әзерләү өчен бер үк төрле вакыт бирелә.

Конкурс комиссиясе бәяләмәләрне бәяли, кирәк булганда – материалны бәян итүнең сыйфаты һәм тирәнлеген, мәсьәләне ни дәрәҗәдә тулы ачуны бәяли. Реферат нигезләмәләренең яңалыгы һәм фәнни кыйммәте белән аерылып торуы хуплана.

4.4.11. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә кандидатлар дәгъва кыла торган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфалары) ия булган структур подразделение җитәкчесе үткәрелгән тест, рефератны һәм индивидуаль әңгәмәне бәяләү нәтиҗәләре буенча һәр кандидатка бәяләмә әзерли.

4.4.12. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертү) дәгъва кылучы кандидатларга тест уздыру Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан раслана торган тест уздыру методикасы нигезендә хәл ителә.

4.4.13. Тест узган кандидатлар белән индивидуаль әңгәмә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан үткәрелә.

Индивидуаль әңгәмә конкурс әгъзалары тарафыннан кандидатларның булачак һөнәри хезмәт эшчәнлеге темасы буенча бирелә торган сорауларга кандидатларның телдән җавапларыннан гыйбарәт, әңгәмә барышында конкурс комиссиясе, гражданлык хезмәте вазыйфасына карата тиешле квалификация таләпләреннән һәм бу вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның башка нигезләмәләреннән, шулай ук бу Нигезләмәдә һәм дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе һәм

Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән бүтән нигезләмәләрдән чыгып, кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяли.

4.5. Конкурсның икенче этабы нәтиҗәсе булып һәм бер үк вакытта конкурсның йомгаклау нәтиҗәсе булып конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелгән конкурс комиссиясе карары тора.

4.6. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә конкурс йомгакларын үткәрүгә һәм гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) кандидат турында карар кабул итүгә нигез булып кандидатлар җыйган тавышлар саны, кандидатлар дәгъва кылган вазыйфалы структур подразделение җитәкчесенең фикере тора.

4.7. Конкурс үткәрү нәтиҗәсендә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасы) буенча кирәкле барлык таләпләргә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаган очракта, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынауларын үткәрү яки яңа конкурс үткәрү турында тәкъдим кертү хакында карар кабул итүгә хокуклы.

4.8. Гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына конкурста җиңүчене билгеләү турында җитәкче боерыгы чыгарыла һәм җиңүче белән хезмәт контракты төзелә. Конкурс комиссиясе шулай ук гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңмәгән, әмма һөнәри һәм шәхсән сыйфатлары югары бәяләнгән кандидатны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең кадрлар резервына кертү турында тәкъдим итү характерындагы карар кабул итүгә хокуклы.

Кандидатның ризалыгы белән аны гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына керүче шул ук төркемдә гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен кадрлар резервына кертү турында җитәкче боерыгы чыгарыла.

Конкурста җиңүчене – гражданлык хезмәткәрен (гражданин) кадрлар резервына кертү җитәкче боерыгы белән рәсмиләштерелә.

4.9. Конкурс нәтиҗәләре турында хәбәрләр конкурс тәгәлләнгәннән соң 7 көн эчендә кандидатларга язмача рәвештә җибәрелә, шул ук вакытта, конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвештә җибәргән кандидатларга – дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә. Шушы ук срокта конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге мәгълүмат системасының рәсми сайтларына урнаштырыла.

4.10. Кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законы нигезендә шикаять белдерүгә хокуклы.

4.11. Конкурста катнашуга кертелмәгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучыларның документлары һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс тәгәлләнгәннән соң өч ел эчендә язмача гариза нигезендә үзләренә кире кайтарып бирелергә мөмкин. Моңа кадәр документлар Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе архивында саклана, шуннан соң юкка чыгарыла. Электрон рәвештә тапшырылган конкурста катнашу өчен документлар өч ел дәвамында саклана. Шуннан соң алар юкка

чыгарылырга тиеш.

4.12. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына барып кайту, торак наймы, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һ.б. чыгымнары) кандидатларның үз средстволары хисабына хәл ителә.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти

гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесенә

___________________________________________
( фамилиясе, исеме, атасының исеме)

___________________________________________

___________________________________________

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда),

___________________________________________
яшәү адресы; гариза тапшыру

___________________________________________
вакытына эш урыны, вазыйфасы)

___________________________________________
(мобиль телефоны, эл.почтасы)

Гариза

Мине Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасын: ______________________________________________________ биләү (кадрлар
(вазыйфа һәм подразделение атамасы)
резервына кертү) өчен Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашуга кертүегезне сорыйм.

“Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль закон, “Татарстан Республикасының дәүләти гражданлык хезмәте турында” 16 гыйнвар, 2003 ел, № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 1 февраль, 2005 ел, № 112 Россия Федерациясе Президенты Указы, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс үткәрү турында нигезләмә, шул исәптән вакантлы вазыйфага карата куела торган квалификация таләпләре белән таныштым.

“Персональ мәгълүматлар турында” 27 июль, 2006 ел, 152-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм.

Конкурс үткәрү датасы һәм урыны турында E-mail яки югарыда күрсәтеп үтелгән мобиль телефон номерына СМС-хәбәр җибәрүгә ризалык бирәм.

Гаризага кушып бирәм: _______________________________________________
(кушып бирелә торган документларны санап үтәргә)

“___” ____________ 20 ел ________________ ___________
(имза) (тулы имза)